# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында янгыннан**
**ирекле саклау турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның кулланылыш даирәсе**

Әлеге Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасында янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары яисә катнашучылары булып торучы һәм (яисә) янгыннарны сүндерүдә турыдан-туры катнаша торган янгыннан ирекле саклау бүлекчәләре белән хезмәт мөнәсәбәтләренә кергән Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга, шулай ук Татарстан Республикасында янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә кагыла.

2 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр "Янгыннан ирекле саклау турында" 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон) мәгънәсендә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау оештыруның һәм аның эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау оештыруның һәм аның эшчәнлегенең хокукый нигезе Россия Федерациясе Конституциясеннән, федераль конституциячел законнардан, Федераль законнан, башка федераль законнардан һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларыннан, әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларыннан һәм муниципаль хокукый актлардан гыйбарәт.

4 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген тәэмин итүдә катнашуы**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары ирекле янгын сүндерүчеләрнең һәм янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итәләр, шулай ук аларның эшчәнлекләре гамәлгә ашырылганда Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар кысаларында тиешле бюджет акчалары исәбеннән ярдәм итә һәм ирекле янгын сүндерүчеләрне хокукый һәм социаль яклау чаралары системасын күз алдында тота алалар.

5 статья. **Янгыннан ирекле саклау мөлкәте**

Янгыннан ирекле саклау мөлкәте гамәлгә куючының (гамәлгә куючыларның) мөлкәтен озак сроклы нигездә янгыннан ирекле саклау командасына (дружинасына) биләүгә, арендага һәм (яисә) түләүсез файдалануга тапшыру, кертемнәр һәм иганәләр, янгыннан ирекле саклау командасы (дружинасы) уставы нигезендә үткәрелә торган чаралардан кергән керемнәр ярдәмендә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә күрсәтелә торган ярдәм чаралары һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка керемнәр исәбеннән туплана.

6 статья. **Дәүләт ярдәме чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләре**

Әлеге Законда каралган дәүләт ярдәме чаралары янгыннар сүндерүдә турыдан-туры катнашучы ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә күрсәтелә.

7 статья. **Янгыннан ирекле саклау эшчәнлеген координацияләү**

Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау буенча территориаль командалар (дружиналар) бүлекчәләрен берләштерүче һәм аларның эшчәнлеген координацияләүче янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмә төзелергә мөмкин.

8 статья. **Ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә күрсәтелә торган дәүләт ярдәме чаралары**

Янгыннан ирекле саклау командалары (дружиналары) составында янгыннар сүндерүдә турыдан-туры катнашкан ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан

ирекле саклау хезмәткәрләренә салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салымнар һәм җыемнар түләү буенча ташламалар бирелергә мөмкин.

9 статья. **Янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә күрсәтелә торган дәүләт ярдәме чаралары**

Янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә дәүләт ярдәме күрсәтү түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) финанс, мөлкәти, мәгълүмати, консультатив ярдәм итү, шулай ук янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр хезмәткәрләрен һәм анда катнашырга теләүчеләрне әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү өлкәсендә ярдәм итү;

2) янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә салымнар һәм җыемнар түләү буенча ташламалар бирү;

3) янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрдә "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказларны урнаштыру турында" 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру;

4) янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен арендага һәм (яисә) түләүсез файдалануга тапшыру.

10 статья. **Янгыннан ирекле саклауга җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган ярдәм чаралары**

Җирле үзидарә органнары янгыннан ирекле саклауга җирле бюджетлар акчалары исәбеннән ярдәм чаралары билгеләргә хокуклы.

11 статья. **Ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә иминият гарантияләре һәм социаль гарантияләр**

1. Янгыннар сүндерүдә катнашуга, һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга, янгыннар вакытында кешеләрне һәм мөлкәтне коткаруга һәм зыян күргәннәргә беренче ярдәм күрсәтүгә янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен һәм ирекле янгын сүндерүчеләрне җәлеп итүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тиешле бюджетта күрсәтелгән органнарны тотуга каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән ярдәм күрсәтү тәртибендә янгыннан ирекле саклау буенча территориаль бүлекчәләрнең ирекле янгын сүндерүчеләрен алар ирекле янгын сүндерүче вазыйфаларын башкарган чорда шәхси иминләштерүне гамәлгә ашырырга мөмкин.

2. Янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен һәм ирекле янгын сүндерүчеләрне, шулай ук аларның гаилә әгъзаларын, шул исәптән янгыннан ирекле саклау хезмәткәре яисә ирекле янгын сүндерүче үз вазыйфаларын башкарган

чорда һәлак булган очракта, хокукый һәм социаль яклау чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон рәсми басылып чыккан көннән алып өч ай эчендә аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 48-ТРЗ